МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

№ 155/о

ПРИКАЗ | БОЕРЫК

"05" 09 2017

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының Проект документациясенә һәм (яисә) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" 2016 елның 11 октябрендәге 167/о номерлы боерыгы белән расланган Проект документациясенә һәм (яисә) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Предметы капиталь төзелеш объектларын бер үк вакытта проектлау, төзү һәм эксплуатациягә кертү буенча эшләр башкарудан гыйбарәт булган контрактларны төзү тәртибе һәм нигезләре турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында" 2017 елның 12 маендагы 563 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының "Проект документациясенә һәм (яисә) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" 2016 елның 11 октябрендәге 167/о номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2017 елның 20 апрелендәге 79/о номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Проект документациясенә һәм (яисә) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (алга таба – Регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.4 пунктның унбишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасының төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя хасил итү идарәсе" дәүләт автономияле учреждениесен булдыру турында"

2015 елның 20 февралендәге 102 номерлы карары (алга таба – 2015 елның 20 февралендәге 102 номерлы ТР МК карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы" журналы, 2015, № 7, 0593 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып)";

"Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге" графасында 2.5 пунктның унсигезенче абзацында "заказлы" сүзен төшереп калдырырга;

"Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге" графасында 2.6 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3. Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрыннан белешмәләр (Дәүләт теркәвенә алу, кадастр һәм картография буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә).";

"Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге" графасының 2.13 пунктында түбәндәге эчтәлекле икенче абзац өстәргә:

"Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гарызнамә ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә";

Регламентның 3 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында башкару үзенчәлекләре

3.1. Мөрәҗәгать итүченең шушы Регламентка 3 нче кушымтада күрсәтелгән документлар пакеты белән "ТР ДЭБХИ" ДАУ мөрәҗәгать итүе дәүләт хезмәтен күрсәтә башлау өчен нигез булып тора.

Проект документациясенә һәм (яисә) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасын үткәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1. мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә;

2. гаризаны һәм документларны теркәлгән документлар пакеты белән кабул итү һәм теркәү;

3. электрон рәвештә белешмәләр бирү турындагы гарызнамәләрне ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы (алга таба – ВЭХС) ярдәмендә җибәрү һәм соралучы документларны (белешмәләрне) алу.

4. дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан тапшырыла торган Документлар исемлегенә (шушы Регламентка 3 нче кушымта) туры китереп Мөрәҗәгать итүче тапшырган документларның тулы булу-булмавын тикшерү яисә документларны кабул итүдән баш тарту;

5. дәүләт хезмәтенең бәясен билгеләү, дәүләт хезмәте күрсәтүгә шартнамә төзү;

6. дәүләт хезмәтен күрсәтү, дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсен бирү (бирүдән баш тарту) турында карар кабул итү;

7. күрсәтелгән дәүләт хезмәтенең бәяләмәсен (бәяләмә дубликатын) төзү һәм бирү;

8. техник хатаны (язу, басма хатасын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү;

9. дәүләт экспертизасы эшен формалаштыру;

10. дәүләт хезмәте күрсәтү буенча Бирелгән бәяләмәләр реестрын алып бару һәм Бирелгән бәяләмәләр реестрыннан мәгълүмат бирү;

11. дәүләт хезмәтен яңадан күрсәтү, бәяләмә дубликаты тапшыру.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең блок-схемасы шушы Регламентка 1 нче кушымтада күрсәтелде.

3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен шәхсән, телефон һәм (яисә) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

"ТР ДЭБХИ" ДАУ белгече мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларның составы, формасы буенча һәм башка мәсьәләләрдә.

"ТР ДЭБХИ" ДАУ белгече мөрәҗәгать итүчене дәүләт хезмәтен алу предметы буенча консультацияли, дәүләт хезмәте күрсәтү турында бланк тапшыра һәм зарурлык булганда гариза бланкын тутыруда ярдәм күрсәтә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документациянең составы, формасы буенча консультацияләр.

3.3. Гаризаны һәм документларны теркәлгән документлар пакеты белән кабул итү һәм теркәү.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтен үткәрү турында гаризаны шәхсән үзе, ышанычлы заты аша яисә почта буенча (кулга тапшырылу турындагы тамга һәм теркәлгәннәрнең исемлеге белән) бирә һәм шушы Регламентның 2.5 пункты нигезендә документлар тапшыра.

Дәүләт хезмәтен үткәрү турында гариза тапшырылган көннән соңгы өч эш көне эчендә документларны кабул итү белән шөгыльләнүче "ТР ДЭБХИ" ДАУ белгечләре, шушы Регламентның 3 нче кушымтасына туры китереп, зарури документларның булу-булмавын тикшерәләр.

3.4. Ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә электрон рәвештәге белешмәләрне бирү турында гарызнамәләр җибәрү һәм соралучы документларны (белешмәләрне) алу.

Техник хезмәт белгече ВЭХС ярдәмендә электрон рәвештә түбәндәгечә гарызнамәләр җибәрә:

Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан яисә Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр бирү турында;

Дәүләт теркәвенә алу, кадастр һәм картография буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрыннан белешмәләр бирү турында.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза кергән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турындагы гарызнамәләр.

Сорала торган документлар (белешмәләр) белешмәләрне җиткерүче тарафыннан законнарда билгеләнгән вакытларда җибәрелгән гарызнамәләр нигезендә тапшырыла.

3.5. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен, Мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан тапшырыла торган Документлар исемлегенә (шушы Регламентка 3 нче кушымта) туры китереп, Мөрәҗәгать итүче тапшырган документларның тулы булу-булмавын тикшерү яисә документларны кабул итүдән баш тарту.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен, шушы Регламентка 3 нче кушымтага туры китереп, Мөрәҗәгать итүче тапшырган документларның тулы булу-булмавын тикшерү. Зарури документларның булмавы, тапшырылган документларның таләпләргә җавап бирмәү фактлары билгеләнгән очракта, "ТР ДЭБХИ" ДАУ белгече Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен каршылыклар булуы хакында хәбәр итә һәм Мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган документларда ачыкланган җитешсезлекләрнең эчтәлеген аңлата һәм аларны юкка чыгару буенча чаралар күрергә киңәш итә.

Кәгазьдә тапшырылган документлар (дәүләт экспертизасын үткәрү турындагы гаризадан тыш) Мөрәҗәгать итүчегә кайтарып бирелә. Электрон рәвештә тапшырылган документлар (дәүләт экспертизасын үткәрү турындагы гаризадан тыш) бәяләмә теркәлгән вакыттан алып кимендә 3 ай дәвамында сакланырга тиешле.

Язмача баш тарту заказлы хат итеп җибәрелә яисә Мөрәҗәгать итүченең кулына гариза тапшырылган көннән соңгы өч эш көне эчендә бирелә. Баш тарту турында хәбәр итү телефон аша, язмача яисә электрон рәвештә дә башкарылырга мөмкин.

Документлар, шул исәптән электрон рәвештә тапшырылганнары да, тулы булмаган очракта, Мөрәҗәгать итүченең язмача гарантиясе булганда, Мөрәҗәгать итүче тарафыннан язмача гарантия тапшырылган вакыттан алып 10 эш көне дәвамында, тупланып беткәнчегә кадәр, кайтарып бирелми.

Документлар пакеты федераль законнарда билгеләнгән таләпләргә (шушы Регламентка 3 нче кушымта) җавап биргән очракта гариза теркәлә һәм электрон белешмәләр базасына кертелә, дәүләт экспертизасының бәясен билгеләү өчен техник хезмәткә тапшырыла.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза кергән һәм зарури документлар тапшырылган вакыттан алып өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәтен үткәрү өчен гаризаны теркәү һәм дәүләт хезмәтенең бәясен билгеләү өчен техник хезмәткә тапшыру, яисә дәүләт экспертизасын үткәрүдән баш тарту турында хәбәр җибәрү.

Җаваплы – "ТР ДЭБХИ" ДАУ техник хезмәт җитәкчесе.

3.6. Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең бәясен билгеләү, дәүләт хезмәте күрсәтүгә шартнамә төзү.

Техник хезмәт белгече дәүләт хезмәтенең бәясен билгели һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен түләү күләме хисапланган, "ТР ДЭБХИ" ДАУ ягыннан

имзаланган шартнамә проектын (алга таба – шартнамә) Мөрәҗәгать итүчегә җибәрә (тапшыра). Шартнамә проекты (шушы Регламентка 2 нче кушымта) Мөрәҗәгать итүчегә электрон рәвештә дә җибәрелергә мөмкин.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза килгән вакыттан башлап өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: дәүләт экспертизасын үткәрү буенча шартнамә проектын Мөрәҗәгать итүчегә җибәрү.

Җаваплы – "ТР ДЭБХИ" ДАУ техник хезмәт белгече.

3.7. Дәүләт хезмәтен күрсәтү, дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсен бирү (бирүдән баш тарту) турында карар әзерләү һәм кабул итү.

3.7.1. Шартнамә имзаланганнан соң һәм дәүләт хезмәтен үткәрүгә түләү кертелүне раслый торган документлар Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылгач, шушы объект беркетелгән бүлекнең җаваплы белгече ике эш көне эчендә проект документациясенең бүлекләрен тиешле бүлекләргә яисә шартнамә нигезендә экспертиза үткәрүгә җәлеп ителгән оешмаларга һәм (яисә) белгечләргә локаль эксперт бәяләмәләрен бирү чорын билгеләп җибәрә, мәгълүматны объектның карточкасына кертә.

3.7.2. Нигезләмәнең 35 пункты нигезендә, дәүләт экспертизасын үткәрү барышында проект документациясендә бәяләмә әзерләргә мөмкинлек бирми торган җитешсезлекләр (белешмәләрнең, тасвирламаларның, исәпләмәләрнең, сызымнарның, схемаларның һ.б. булмавы яисә тулы булмавы) ачыкланган очракта, "ТР ДЭБХИ" ДАУ Мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган җитешсезлекләр турында язмача яисә электрон рәвештә хәбәр итә.

Җитешсезлекләрне юкка чыгару вакыты алар Мөрәҗәгать итүче тарафыннан алынган вакыттан башлап сигез эш көненнән артык була алмый.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар шартнамә имзаланган һәм дәүләт экспертизасын үткәрү өчен түләү кертелгән вакыттан башлап 10 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: локаль эксперт бәяләмәсен төзү, җитешсезлекләр турында Мөрәҗәгать итүчегә хәбәр җибәрү.

3.7.3. Әгәр дә ачыкланган җитешсезлекләрне дәүләт экспертизасы барышында юкка чыгару мөмкин булмаса яисә Мөрәҗәгать итүче билгеләнгән чорда аларны бетермәсә, "ТР ДЭБХИ" ДАУ алга таба дәүләт экспертизасын үткәрүдән баш тартырга һәм фактта күрсәтелгән хезмәтләрне түләп, шартнамәне вакытыннан алда таркату мәсьәләсен күтәрергә хокуклы, бу хакта кабул ителгән карар сәбәпләрен күрсәтеп, Мөрәҗәгать итүчегә язмача хәбәр итә.

Әгәр дә дәүләт экспертизасының тискәре бәяләмәсе өчен нигез булып хезмәт иткән җитешсезлекләрне кәгазьдә тапшырылган документларны кайтарып бирмичә бетерергә мөмкин булса һәм Мөрәҗәгать итүче мондый документларның кайтарып бирелүен таләп итмәсә, ул вакытта мондый җитешсезлекләр 10 эш көненнән артмый торган чорда төзәтелә. Бу очракта дәүләт экспертизасына тапшырылган документлар Мөрәҗәгать итүчегә кайтарылмый. Аларны җиренә җиткереп эшләп бетергәннән соң Мөрәҗәгать итүче кертелгән үзгәрешләре белән проект документациясенең һәм (яисә) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренең бер өлешен һәм шушы үзгәрешләрне тасвирлаган белешмәне (кисәтүләргә җавапларны) "ТР ДЭБХИ" ДАУ тапшыра.

3.8. Күрсәтелгән дәүләт хезмәтенең бәяләмәсен төзү һәм бирү.

3.8.1. Ачыкланган җитешсезлекләргә җаваплар һәм үзгәртелгән документлар алынганнан соң алар дәүләт экспертизасы бәяләмәсен төзү өчен "ТР ДЭБХИ" ДАУ җаваплы белгеченә тапшырыла. Башкару турындагы белешмәләр бер үк вакытта дәүләт экспертизасы объектының карточкасына кертелә.

"ТР ДЭБХИ" ДАУ җаваплы белгече 887/пр номерлы Боерык нигезендә уңай (тискәре) бәяләмә (шушы Регламентка 7 нче кушымта) төзи һәм раслау өчен аны "ТР ДЭБХИ" ДАУ башлыгына тапшыра.

Дәүләт экспертизасы бәяләмәсе дәүләт экспертизасын үткәрүдә катнашучы экспертлар тарафыннан имзалана, "ТР ДЭБХИ" ДАУ башлыгы яисә аның вазыйфаларын үтәүче вазыйфаи зат тарафыннан раслана һәм эш башкару тәртибендә теркәү өчен тапшырыла.

Электрон рәвештә әзерләнгән дәүләт экспертизасы бәяләмәсе дәүләт экспертизасын үткәрүдә катнашучы экспертлар тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза ярдәмендә имзалана һәм "ТР ДЭБХИ" ДАУ башлыгы яисә аның вазыйфаларын үтәүче вазыйфаи зат тарафыннан раслана һәм эш башкару тәртибендә теркәү өчен тапшырыла.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар җитешсезлекләре бетерелгән, үзгәртелгән документация Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылганнан соңгы 10 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: дәүләт экспертизасын үткәрүдә катнашкан экспертлар тарафыннан имзаланган һәм "ТР ДЭБХИ" ДАУ башлыгы тарафыннан расланган һәм теркәү өчен тапшырылган уңай (тискәре) дәүләт экспертизасы бәяләмәсе.

3.8.2. Теркәлгән бәяләмә Мөрәҗәгать итүченең кулына яисә аның ышанычлы затына тапшырыла, яисә хәбәрләмәле заказлы хат итеп җибәрелә.

Уңай дәүләт экспертизасы бәяләмәсе дүрт нөсхәдә тапшырыла. Тискәре бәяләмә – бер нөсхәдә.

Бәяләмәне алу өчен Мөрәҗәгать итүче "ТР ДЭБХИ" ДАУ шәхесен таныклаучы документны, Мөрәҗәгать итүченең вәкиле юридик затның законлы вәкиле тарафыннан таныкланган ышанычнамәне һәм шәхесен таныклаучы документны күрсәтергә тиеш.

Кәгазьдә тапшырылган проект документациясе, проектлау биременең күчермәсе, инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләре һәм инженерлык эзләнүләрен башкару биременең күчермәсе Мөрәҗәгать итүчегә шартнамәдә билгеләнгән чорларда һәм тәртиптә кайтарып бирелергә тиеш. Аталган, электрон рәвештә тапшырылган документлар кайтарып бирелми.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар бәяләмә "ТР ДЭБХИ" ДАУ башлыгы тарафыннан расланган вакыттан алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: теркәлгән дәүләт экспертизасы бәяләмәсен Мөрәҗәгать итүчегә бирү.

3.9. Техник хаталарны (язу, хәреф хаталарын, грамматик яки арифметик хаталарны) төзәтү.

Элегрәк бирелгән бәяләмәдә җибәрелгән техник хаталарны (язу, хәреф хаталарын, грамматик яки арифметик хаталарны) төзәтүгә бәйле рәвештә дәүләт

экспертизасы бәяләмәсен үзгәртеп рәсмиләштерү гамәлгә ашырыла.

Дәүләт экспертизасын үзгәртеп рәсмиләштерү шушы Регламентка 8 нче кушымтага туры китереп төзелгән, теркәлгән гариза нигезендә гамәлгә ашырыла, ул төзәтелергә тиешле техник хаталарны күрсәтеп, ирекле рәвештә тапшырыла. Гаризага дәүләт хезмәтен күрсәтүнең нәтиҗәсе буларак техник хатасы булган дәүләт экспертизасы бәяләмәләре һәм техник заказчы (төзүче) исеменнән эш йөртүгә Мөрәҗәгать итүченең вәкаләтләрен раслый торган документ теркәлә.

3.9.1. "ТР ДЭБХИ" ДАУ белгече:

техник хатаны (язу, басма хатасын, грамматик яисә арифметик хатаны) төзәтү турында гаризаны кабул итә һәм терки;

гариза "ТР ДӘБХИ" ДАУ башлыгы тарафыннан каралганнан соң, башлык дәүләт экспертизасы бәяләмәсенә үзгәрешләр кертү яисә үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында җавап әзерләү турындагы резолюциягә кул куя, башкару өчен җаваплы белгечне билгели.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза кергәннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән, үтәү өчен җаваплы белгечкә тапшырылган техник хатаны (язу, басма хатасын, грамматик яисә арифметик хатаны) төзәтү турында гариза.

3.9.2. Җаваплы белгеч:

"ТР ДЭБХИ" ДАУ башлыгының дәүләт экспертизасы бәяләмәсенә үзгәрешләр кертү турында яисә үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында боерык проектын әзерли;

"ТР ДЭБХИ" ДАУ башлыгының боерык проектын килештерү өчен "ТР ДЭБХИ" ДАУ башлыгына (ул булмаганда, аның тарафыннан вәкаләт бирелгән затка) җибәрә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза Бүлеккә җибәрелгән вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: килештерү өчен "ТР ДЭБХИ" ДАУ башлыгына җибәрелгән боерык проекты.

3.9.3. "ТР ДЭБХИ" ДАУ башлыгы (ул булмаганда – аның тарафыннан вәкаләт бирелгән зат) дәүләт экспертизасы бәяләмәсен үзгәртеп рәсмиләштерү турында яисә дәүләт экспертизасы бәяләмәсенә үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында боерыкны раслый. Имзаланган боерык җаваплы белгечкә җибәрелә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура раслау өчен проект килгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт экспертизасы бәяләмәсен үзгәртеп рәсмиләштерү турында яисә дәүләт экспертизасы бәяләмәсенә үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында боерык.

3.9.4. Дәүләт экспертизасына үзгәрешләр кертү турында карар кабул ителгән очракта белгеч Мөрәҗәгать итүчегә, техник хатаны төзәтү турындагы гаризада яисә дәүләт экспертизасын үткәрү турындагы гаризада күрсәтелгән элемтә ысулыннан файдаланып, дәүләт экспертизасының әзерлеге турында хәбәр итә һәм Мөрәҗәгать итүченең теләгенә карап:

әгәр дә Мөрәҗәгать итүче шәхсән үзе алу теләген белдергән булса, үзгәртеп рәсмиләштерелгән дәүләт экспертизасы бәяләмәсенең тапшырылу датасын һәм

вакытын хәбәр итә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар беренче дәүләт экспертизасы бәяләмәсенә үзгәрешләр кертелгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: дәүләт экспертизасы бәяләмәсен алу ысулын Мөрәҗәгать итүче белән килештерү.

Үзгәрешләр кертүдән баш тарткан очракта Мөрәҗәгать итүчегә язмача җавап бирелә.

3.9.5. Мөрәҗәгать итүчегә техник хатасы төзәтелгән дәүләт хезмәте нәтиҗәсен тапшыру.

Җаваплы белгеч, Мөрәҗәгать итүченең ихтыярына карап, бәяләмәне яисә дәүләт экспертизасы бәяләмәсенә үзгәрешләр кертүдән баш тарту турындагы җавапны тапшыра (җибәрә).

Процедураның нәтиҗәсе: техник хатасы төзәтелгән, мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган дәүләт экспертизасы бәяләмәсе.

3.10. Дәүләт экспертизасы эшен формалаштыру.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт экспертизасы эше ачыла. Дәүләт экспертизасы эшләре даими саклана торган архив документларына карый. Аларны юкка чыгару, шулай ук төзәтү һәм (яисә) аларда булган документларны алу рөхсәт ителми.

Дәүләт экспертизасы эшенә түбәндәгеләр урнаштырыла:

1) дәүләт экспертизасын үткәрү турында гариза;

2) шартнамә күчермәсе;

3) шартнамә нигезендә экспертиза үткәрү өчен җәлеп ителгән оешмалар һәм (яисә) белгечләр тарафыннан ясалган нәтиҗәләрне үз эченә алган документлар;

4) дәүләт экспертизасы бәяләмәсе;

5) Мөрәҗәгать итүченең карточкасы;

6) дәүләт экспертизасын үткәрүгә бәйле булган, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән башка төрле документлар (документларның күчермәләре).

Әгәр дә проект документациясе һәм (яисә) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләре, шулай ук шушы Регламентта каралган башка төрле документлар электрон рәвештә тапышырылган булсалар, дәүләт экспертизасы эше электрон рәвештә алып барыла һәм анда дәүләт экспертизасын үткәрү өчен тапшырылган барлык документлар кертелә. Электрон рәвештә тапшырылган документларга төзәтмәләр кертү һәм аларны юкка чыгару рөхсәт ителми.

3.11. Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча Бирелгән бәяләмәләр реестрын алып бару һәм Бирелгән бәяләмәләр реестрыннан мәгълүмат бирү.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча Бирелгән бәяләмәләр реестрын алып бару һәм Бирелгән бәяләмәләр реестрыннан мәгълүмат бирү Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы буенча федераль агентлыкның "Проект документациясенә һәм инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә бирелгән дәүләт экспертизасы бәяләмәләре реестрын алып бару һәм бу Реестрда булган белешмәләрне бирү тәртибе турында" 2007 елның 2 июлендәге 186 номерлы боерыгы белән җайга салына.

3.12. Дәүләт хезмәтен яңадан күрсәтү, бәяләмә дубликаты тапшыру.

Дәүләт хезмәтен яңадан күрсәтү Нигезләмәнең 44, 45 пунктларына туры

китереп гамәлгә ашырыла:

шушы Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән очракларда;

әгәр дә беренче мәртәбә (кабат үткәрелүче алдыннан башкарылган) дәүләт экспертизасын үткәргәннән соң Россия Федерациясе законнарына дәүләт экспертизасы нәтиҗәләренә йогынты ясарга мөмкин булган үзгәрешләр кертелсә, тапшырылган инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләре эксперт бәяләвенә тулы күләмдә дучар ителергә мөмкин.

Яңадан дәүләт экспертизасын үткәрү шушы Регламентта беренче дәүләт экспертизасын үткәрү өчен каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Дәүләт экспертизасы бәяләмәсен югалткан очракта, мөрәҗәгать итүче дәүләт экспертизасын үткәрү буенча оешмадан бу бәяләмәнең дубликатын алырга хокуклы. Дубликатны тапшыру түләүсез нигездә язмача мөрәҗәгать алынган датадан соң 10 календарь көне эчендә гамәлгә ашырыла.

3.13. Дәүләт хезмәте күпфункцияле үзәкләрдә, күпфункцияле үзәкләрнең читтән торып эшләү урыннарында күрсәтелми.";

Регламентка 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Проект документациясенә дәүләт
экспертизасы һәм (яисә) инженерлык
эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт
экспертизасы буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ
регламентына 2 нче кушымта

Рәвеше

**Түләүле хезмәтләр күрсәтү**
**шартнамәсе**

Казан ш. ______________________________

_____________________ нигезендә гамәл кылучы ________________ йөзендә "Татарстан Республикасының төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя хасил итү идарәсе" дәүләт автономияле учреждениесе ("ТР ДЭБХИ" ДАУ), алга таба "Башкаручы" булып исемләнеп, бер яктан, һәм __________________ нигезендә гамәл кылучы _________________________ йөзендә, алга таба "Заказчы" буларак исемләнеп, икенче яктан, алга таба "Яклар" дип исемләнеп, шушы шартнамәне төзеделәр, түбәндәгеләр хакында:

## 1. Шартнамә предметы

1.1. Проект документациясенә һәм (яисә) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасын үткәрүгә шушы шартнамә шартлары буенча Башкаручы Заказчының гаризасы буенча "_________________________" дәүләт

экспертизасын үткәрү (алга таба – хезмәтләр, дәүләт экспертизасы) бурычын, ә Заказчы бу хезмәт өчен түләү һәм дәүләт экспертизасын үткәрү нәтиҗәләрен кабул итеп алу бурычын үз өстенә ала.

1.2. Проект документациясенә дәүләт экспертизасын үткәрү Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Проект документациясенә һәм инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасын оештыру һәм үткәрү турында" 2007 елның 5 мартындагы 145 номерлы карары белән расланган Проект документациясенә һәм инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасын үткәрүне оештыру турында нигезләмәдә (алга таба – Нигезләмә), Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Проект документациясе бүлекләренең составы һәм аларның эчтәлегенә карата таләпләр турында" 2008 елның 16 февралендәге 87 номерлы карарында һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы бүтән норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртип нигезендә гамәлгә ашырыла.

1.3. Дәүләт экспертизасын үткәрү нәтиҗәсе булып Башкаручының Заказчы тарафыннан тапшырылган проект документациясенең техник регламентлардагы таләпләргә һәм инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә, проект документациясе бүлекләренә карата таләпләргә җавап бирүе (уңай бәяләмә) яисә җавап бирмәве (тискәре бәяләмә) турында, шулай ук, әгәр дә инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә экспертиза гамәлгә ашырылса, инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренең техник регламентлардагы таләпләргә җавап бирүе турында бәяләмәсе тора.

## 2. Дәүләт экспертизасын үткәрү буенча хезмәтләргә түләү һәм исәп-хисап ясау тәртибе

2.1. Экспертизаның бәясе Нигезләмә нигезендә билгеләнә.

2.2. Шушы Шартнамәнең 1.1 пункты нигезендә Заказчы дәүләт экспертизасын үткәрү өчен Башкаручыга түләү күләменә (Шартнамәгә 1 нче кушымта) туры китереп, бәясен түли, аның күләме – ____________ тәшкил итә, шул исәптән 18%лы ставка буенча НДС.

Дәүләт экспертизасын үткәрү барышында проект документациясенең, инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренең күләме арткан очракта һәм (яисә) каралучы проект документациясе буенча проект-эзләнү эшләренең бәясе үзгәртелгәндә Шартнамә буенча экспертизаның бәясе тәгаенләнергә тиеш.

2.3. Хезмәткә түләү дәүләт экспертизасының нәтиҗәсе нинди булуга бәйсез рәвештә түләнә.

2.4. Заказчы шушы шартнамә имзаланган вакыттан башлап биш эш көне эчендә хезмәтләр бәясенең 100%ы күләмендә аванс түләү бурычын үз өстенә ала. Счет түләүнең нигезе булып тора. Башкаручы аванс суммасы килгән көннән башлап исәпләнә торган биш календарь көненнән соңга калмыйча Заказчыга күрсәтеләчәк хезмәтләр өчен счетка аванс түләве буенча счет-фактура бирә.

2.5. Счетны түләү көне булып акча чараларының Башкаручының исәп-хисап счетына килгән, банк өземтәсендә расланган көн санала.

2.6. Түләү Заказчының язмача күрсәтмәсе нигезендә акча чараларын өченче зат тарафыннан Башкаручының исәп-хисап счетына күчерү юлы белән башкарылырга мөмкин.

## 3. Дәүләт экспертизасын үткәрү вакыты

3.1. Башкаручының исәп-хисап счетына шушы Шартнамәнең 2 нче бүлегендә күрсәтелгән беренче түләм килгәннән соң Башкаручы 30 эш көне эчендә тапшырылган проект документациясенә дәүләт экспертизасын үткәрә һәм бәяләмә әзерли.

Дәүләт экспертизасын үткәрү вакыты Заказчының язмача мөрәҗәгате нигезендә иң күбе 30 көнгә озайтылырга мөмкин.

3.2. Башкаручы билгеләнгән тәртиптә шартнамә мөнәсәбәтләре рәсмиләштерелгән һәм Заказчы тарафыннан Нигезләмә (28 пункты) һәм Шартнамә (2.5 пункты) нигезендә хезмәтнең тулысынча бәясе түләнгән көннән соңгы көннән экспертизаны үткәрә башлый.

3.3. Дәүләт экспертизасын үткәрү буенча хезмәт күрсәтелүе Яклар тарафыннан имзаланган, Башкаручы раслаган рәвештәге Дәүләт экспертизасы буенча күрсәтелгән хезмәтләрне кабул итү акты (алга таба – Акт) (Шартнамәгә 2 нче кушымта) белән раслана.

Әгәр дә Заказчы Актка кул куюдан баш тартса, ул вакытта ул Башкаручыга Актны алган һәм Башкаручы тарафыннан хезмәт күрсәтелгән көннән соңгы биш календарь көне эчендә язмача баш тартуны тапшырырга бурычлы. Әгәр дә Заказчы тарафыннан Башкаручыга билгеләнгән вакытларда дәлилле баш тарту тапшырылмаса, Акт Заказчы тарафыннан имзаланган һәм хезмәт Башкаручы тарафыннан тулы күләмендә нинди дә булса ризасызлыкларсыз күрсәтелгән дип исәпләнә. Дәлилле баш тартуда шушы Шартнамәдә каралган бурычлар кысасыннан чыкмаган кисәтүләр булырга тиеш.

## 4. Якларның хокуклары һәм бурычлары

4.1. Заказчының хокуклары:

4.1.1. Дәүләт экспертизасын үткәрү барышы турында мәгълүмат алу һәм Башкаручыга зарури аңлатмаларны, өстәмә белешмәләрне һәм документларны тапшыру.

4.1.2. Башкаручыга, Заказчының шәхси кабинетыннан файдаланып, электрон документлар рәвешендәге өстәмә документацияне тапшыру.

Оператив рәвештә Башкаручы тарафыннан күрсәтелгән җитешсезлекләрне бетерү өчен проект документациясенә үзгәрешләр кертү.

4.2. Заказчының бурычлары:

4.2.1. Рәсмиләштерелгән шартнамәгә имза кую һәм Башкаручыга кайтару, шушы шартнамә шартлары нигезендә хезмәтләр өчен түләү.

Хезмәт күсрәтелүнең нәтиҗәсенә бәйсез рәвештә, Акт буенча хезмәтне кабул итү, имзалау һәм уңай яисә тискәре бәяләмә рәсмиләштерелгән датадан соңгы биш календарь көне эчендә Башкаручыга Актны кайтарып бирү һәм счет-фактура алу.

4.2.2. Башкаручының сайтында Заказчының шәхси кабинетыннан файдаланып яисә "Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы" федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, электрон документлар рәвешендә яисә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән очракларда, – кәгазьдә составы һәм эчтәлеге буенча гамәлдәге норматив хокукый актларның таләпләренә җавап бирә торган, дәүләт экспертизасын үткәрү өчен зарури документацияне Башкаручыга тапшыру.

Тапшырылган документларның сыйфатлы һәм дөрес булуы өчен Заказчы җаваплы була.

4.2.3. Башкаручының гарызнамәсе буенча проект документациясендә кулланыла торган конструктив һәм технологик чишелешләрнең исәпләмәләрен, шулай ук инженерлык эзләнүләре материалларын мондый гарызнамәне алган вакыттан соңгы биш көн дәвамында тапшыру.

4.2.4. Шушы Шартнамәнең 6.1 пунктында каралган тәртиптә проект документациясенә үзгәрешләр кертү, җитешсезлекләрне бетерү.

4.3. Башкаручының хокуклары:

4.3.1. Шушы Шартнамә шартлары нигезендә хезмәтләргә түләүләр таләп итү.

4.3.2. Дәүләт хакимияте органнарыннан, аларга буйсынучы оешмалардан дәүләт экспертизасын үткәрү һәм Башкаручыга йөкләнгән вазыйфаларны үтәү өчен зарури материалларны сорату.

4.3.3. Заказчы ризалыгыннан башка дәүләт экспертизасын үткәрү өчен бүтән дәүләти һәм (яисә) дәүләтнеке булмаган оешмаларны, шулай ук белгечләрне җәлеп итү.

4.3.4. Шушы Шартнамәнең 4.2.4 п. нигезендә Башкаручы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә, чикләрдә һәм вакытларда Заказчыга проект документациясенә үзгәрешләр кертүне тәкъдим итү.

4.3.5. Шартнамә буенча Заказчы үзенең вазыйфаларын бозганда, асылда, шушы Шартнамәнең 4.2.2, 4.2.3 пунктларында күрсәтелгән техник документация тапшырылмаганда, түләнмәгәндә (шушы Шартнамәнең 2.2, 2.4 пунктлары), Башкаручыга шартнамәне үтәүгә каршы төшелгәндә, шулай ук күрсәтелгән вазыйфаларның билгеләнгән вакытта үтәлмәячәген ачыктан-ачык таныклый торган шартлар булганда хезмәт күрсәтүгә керешмәү, ә күрсәтелә башлаган хезмәтне туктату.

4.3.6. Заказчы тарафыннан шушы Шартнамәнең 2.2 пунктында каралган хезмәтләр күрсәтү бәясен түләү вазыйфалары үтәлмәгәндә хезмәтләрнең нәтиҗәләрен тоткарлап тору (1.3 пункт).

4.3.7. Хезмәт күрсәтүне вакытыннан алда туктату.

4.4. Башкаручының бурычлары:

4.4.1. Шартнамәдә һәм норматив хокукый актларда билгеләнгән вакытларда дәүләт экспертизасын үткәрү.

4.4.2. Тапшырылган документларның саклануын тәэмин итү, шулай ук проект чишелешләре хакында һәм дәүләт экспертизасын үткәрүгә бәйле рәвештә Башкаручыга мәгълүм булган бүтән конфиденциаль мәгълүматны өченче затларга таратмау буенча чаралар күрү.

4.4.3. Шартнамә рәсмиләштерелгәч, хезмәт күрсәтелгәч, хезмәтнең бәясе

тулысынча түләнгәч, Акт нигезендә Заказчыга шушы Шартнамә шартларында уңай яисә тискәре бәяләмә бирү.

4.4.4. Россия Федерациясе законнарында каралган чорларда Заказчыга счет-фактура(лар) рәсмиләштерү һәм бирү (җибәрү).

4.4.5. Эксперт бәяләмәсендә техник хата ачыкланган очракта, биш көн эчендә әлеге хатаны төзәтү һәм Заказчыга төзәтелгән бәяләмәне тапшыру.

## 5. Шартнамәне таркату тәртибе

5.1. Әлеге Шартнамә Заказчы гаризасы нигезендә вакытыннан алда (хезмәт күрсәтелгән чорда) таркатылырга мөмкин, шул ук вакытта гариза кергән вакытка күрсәтелгән хезмәтләрнең бәясе тотып калына. Шушы Шартнамәне туктатуга бәйле рәвештә Башкаручыга китерелгән югалтуларны Заказчы барча эш өчен билгеләнгән түләү күләме белән башкарылган эшкә түләнгән түләү өлеше арасындагы аерма чикләрендә түләргә бурычлы.

5.2. Башкаручы бер яклы тәртиптә, судка мөрәҗәгать итмичә шушы Шартнамәне үтәүдән баш тартырга хокуклы, түбәндәге очракларда:

5.2.1. Заказчы шушы Шартнамәнең 4.2.2, 4.2.3 пунктлары нигезендә документлар тапшыру вакытын уздырып җибәргән очракта;

5.2.2. Заказчы түләү вакытын 30 календарь көненнән артыгракка кичектергәндә;

5.2.3. Заказчы Башкаручыга белә торып төгәл булмаган һәм (яисә) тулы булмаган мәгълүматлар тапшырганда.

5.2.4. Башкаручы белән килештермичә Заказчы тарафыннан проект документациясенә үзгәрешләр кертелгәндә, бу исә законда билгеләнгән чорда хезмәтләр күрсәтүне тәмамлау мөмкинлеген юкка чыгара.

5.2.5. Әгәр дә Башкаручы тарафыннан ачыкланган җитешсезлекләрне дәүләт экспертизасы барышында юкка чыгаруы мөмкин булмаса яисә Заказчы аларны 10 календарь көне эчендә бетермәсә. Проект документациясенең җитешсезлекләре булып проект документациясенең техник регламентларның һәм башка норматив документларның таләпләренә туры килүе яисә туры килмәве турында нәтиҗә ясау мөмкинлеген бирми торган белешмәләрнең, (тасвирламаларның, исәпләмәләрнең, сызымнарның, схемаларның һ.б.) булмавы (тулы булмавы) тора.

5.3. Шушы Шартнамәнең 5.2 пунктында күрсәтелгән шартлар барлыкка килгәндә Башкаручы шартнамәне таркатуның планлаштырылган датасына кадәр 10 эш көненнән соңга калмыйча Заказчыга, таркату датасын күрсәтеп, шушы шартнамәне үтәүдән баш тарту (шартнамәне таркату) турында тиешле язмача хәбәрләмәне җибәрә. Хәбәрләмәдә күрсәтелгән датадан башлап Шартнамә таркатылган булып санала.

5.4. Шушы Шартнамәнең 5.2.1-5.2.5 пунктлары нигезендә әлеге Шартнамә таркатылган очракта Заказчы хезмәтләрнең тулы бәясен түләргә бурычлы.

## 6. Махсус шартлар

6.1. Проект документациясе һәм (яисә) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләре федераль һәм республика законнарындагы таләпләрне бозып үтәлгән очракта, ә

аның күләме һәм эчтәлеге проект чишелешен нигезләү өчен җитәрлек булмаганда, Башкаручы алдан кисәтүләр ясамыйча гына тискәре бәяләмә бирү хокукына ия була.

Дәүләт экспертизасы үткәрелү барышында Заказчы Башкаручының кушуы буенча һәм ул билгеләгән тәртиптә, чикләрдә һәм вакытларда проект документациясенә оператив рәвештә үзгәрешләр кертә һәм (яисә) җитешсезлекләрне бетерә. Эксперт бәясе нигезендә Башкаручы мөстәкыйль рәвештә оператив үзгәрешләр кертү һәм (яисә) җитешсезлекләрне бетерү һәм Заказчыга тиешле күрсәтмәләрне җибәрү мөмкинлеге һәм зарурлыгы турында карар кабул итә.

6.2. Шушы Шартнамәнең 4.2.2, 4.2.3 пунктларында күрсәтелгән документлар Заказчы тарафыннан тапшырылмаган очракта Шартнамә шушы Шартнамәнең 4.2.2, 4.2.3 пунктларында күрсәтелгән документларның Заказчы тарафыннан тапшырылмаган көннәре белән документларны тапшыру датасы арасындагы көннәр саныннан артмаган чорга озынайтыла.

6.3. Заказчы белән документлар һәм мәгълүматлар белән алмашыну Башкаручының рәсми сайтында Заказчының шәхси кабинетыннан файдаланып гамәлгә ашырыла, кәгазьдә җибәрелә торган шартнамә проектыннан һәм Акттан, счет-фактурадан кала.

6.4. Бәяләмәне бирү көчәйтелгән санлы имза белән имзаланган электрон рәвештә, шулай ук, әгәр дә Заказчының гаризасында каралган булса, кәгазь документ рәвешендә гамәлгә ашырыла. Уңай бәяләмә 4 (дүрт) нөсхәдә бирелә. Тискәре бәяләмә 1 (бер) нөсхәдә бирелә.

Билгеләнгән тәртиптә кәгазьдә рәсмиләштерелгән эксперт бәяләмәсен Башкаручы Заказчының вәкиленә түбәндәгеләр булган очракта кулга бирү хокукына ия:

– вәкилдә шушы шартнамә буенча эксперт бәяләмәсен алуга ышанычнамә һәм аның шәхесен таныклый торган документ (паспорт).

6.5. Кәгазьдә тапшырылган проект документациясе, проектлау биременең күчермәсе, инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләре һәм инженерлык эзләнүләрен башкаруга бирем күчермәсе дәүләт экспертизасы үткәрелгәннән соң Заказчыга дәүләт экспертизасы бәяләмәсен тапшыру датасыннан соң бер айдан соңга калмыйча кайтарыла.

6.6. Бу шартнамәгә карата РФ ГК 720 статьясындагы нигезләмәләр кулланылмый.

## 7. Шартнамәдән килеп чыга торган бурычлар үтәлмәгән яисә тиешенчә үтәлмәгән өчен якларның җаваплылыгы, форс-мажор

7.1. Шартнамә буенча бурычларны үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен, шул исәптән дәүләт экспертизасына кәгазьдә тапшырылган документларны үз вакытында кайтарып бирмәү яисә үз вакытында кабул итмәү өчен Яклар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы булалар.

7.2. Әгәр дә шушы Шартнамә буенча бурычларның үтәлмәве күрелмәгән һәм гадәттән тыш холыклы, булдырмый калу мөмкинлеге калмаган вакыйгалар нәтиҗәсендә җиңеп булмый торган көчкә бәйле хәлләр нәтиҗәсендә яисә башка

якның гаебе белән булса, Яклар бурычларны өлешчә яисә тулысынча үтәмәгән өчен җаваплы булудан азат ителә.

7.3. Төп бурыч суммасын түләү вакыты кичектерелгәндә, РФ ГК 317.1 статьясының 1 пункты нигезендә, бу суммага акча чараларыннан файдаланган өчен түләү булып хезмәт итүче процентлар да, РФ ГК 395 статьясында билгеләнгән гражданлык-хокук җаваплылыгы чарасыннан гыйбарәт булган процентлар да өстәлә.

7.4. Шартнамә буенча ризасызлыклар һәм бәхәсләр Якларның сөйләшүләре, ә ризалыкка ирешелмәгән очракта Татарстан Республикасы Арбитраж судына мөрәҗәгать итү юлы белән хәл ителә.

## 8. Йомгаклау нигезләмәләре

8.1. Бу Шартнамә Заказчы тарафыннан документация тулы күләмдә тапшырылган, хезмәткә түләнгән вакыттан башлап үз көченә керә һәм Яклар өчен мәҗбүри була һәм Якларның кара-каршы бурычлары тулысынча үтәлгәнчегә кадәр гамәлдә була.

8.2. Бу Шартнамәгә кертелә торган үзгәрешләр аңа өстәмә килешүләр белән рәсмиләштерелә.

8.3. Хәзергесе белән Яклар үзләренең, аларның аффилир затларының, хезмәткәрләренең яисә арадашчыларының бу Шартнамә имзаланган вакытка кадәр, шулай ук шушы Шартнамә буенча бурычларны үтәү вакытында нинди дә булса хокукка каршы килә торган өстенлекләр алу яисә башка төрле хокукка каршы килә торган максатларга ирешү максатында, шул исәптән бу Шартнамәне имзалату максатларында затларның гамәлләренә яисә карарларына йогынты ясау өчен затларга нинди дә булса акча чараларын түләмәүләре/түләмәячәкләре, тәкъдим итмәүләре/тәкъдим итмәячәкләре һәм түләргә ризалык бирмәүләре/ризалык бирмәячәкләре, шулай ук ришвәт бирү яисә алу, коммерциячел сатып алу кебек квалификацияләнүче, Россия Федерациясенең җинаять юлы белән алынган керемнәрне легальләштерүгә (үзләштерүгә) каршы көрәш турында һәм коррупциягә каршы көрәш турында законнары таләпләрен боза торган гамәлләрне гамәлгә ашырмаулары турындараслыйлар.

Югарыда аталган теләсә кайсы хәл барлыкка килгән очракта бу нигезләмәләрнең бозылуы хакында белеп алган зат бу хакта Якларның җитәкчелегенә кичекмәстән хәбәр итү йөкләмәсен үз өстенә ала.

8.4. Бу Шартнамә бер үк юридик көчкә ия булган 2 (ике) нөсхәдә, һәр якка берәр нөсхәдә төзелде.

8.5. Бу Шартнамәгә түбәндәгеләр теркәлә һәм аның аерылгысыз өлеше булып тора:

1 биттә түләү күләме (шушы Шартнамәгә 1 нче кушымта),

1 биттә Акт (шушы Шартнамәгә 2 нче кушымта).

8.6. Үзләренең адреслары һәм түләү реквизитлары үзгәрүе турында Яклар бер-берсенә 10 көнлек чорда язмача хәбәр итәргә тиеш.

## 9. Якларның адреслары һәм банк реквизитлары:

**Заказчы:**

**БАШКАРУЧЫ**:

"Татарстан Республикасының төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя хасил итү идарәсе" дәүләт автономияле учреждениесе
Юридик адресы: 420073, Казан ш., Шуртыгин ур., 22
Почта адресы: 420054, Татарстан Республикасы, Казан ш., Габдулла Тукай ур., 125.
ИНН 1654017928/ КПП 166001001
Казан ш. "Ак Барс" ХАЖ
Алучы: ТР Финанс министрлыгы ("ТР ДЭБХИ" ДАУ
л/с ЛАВ00713002-УЭкспЦен)
и-х/с 40601810700023000003
БИК 049205805
К/с 30101810000000000805

______________________

____________

Юридик адресы
Почта адресы

БИК
ИНН
КПП

_________

_________________

Шартнамәгә 1 нче кушымта
____________________
____________________

**Торак булмаган күчемсез мөлкәт объектларының проект документациясенә дәүләт экспертизасы үткәрүнең хак ИСӘПЛӘМӘСЕ**

Объект:

Заказчы:

Агымдагы бәяләрдә экспертиза үткәрү хакы:

$$С_{э\ ТЕК} = (Спр \times Ki + Сиз \times Ki) \times П \times НДС$$

**$С_{э\ тек}$ = (сум,**

биредә:

Спр = – 2001 ел бәяләрендә проект документациясен әзерләү хакы.

Сиз = – 2001 ел бәяләрендә эзләнү эшләренең хакы.

Кi =  – 01.01.01 белән чагыштырмача 01.01.15 карата инфляция индексы.

П =  – РФ Хөкүмәтенең 05.03.07 № 145 карарына кушымта нигезендә 2001 елгы бәяләр дәрәҗәсендә дәүләт экспертизасына тапшырылган проект һәм (яисә) тикшеренү эшләренең суммар хакыннан бер өлеш.

**Моннан тыш, 18% НДС –  сум.**
**Башкарылган эшләрнең хакы –  сум.**

**Исәпләмәне башкарды** ______________________________

Шартнамәгә 2 нче кушымта
**№**_______________ _______________

"Татарстан Республикасының төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя хасил итү идарәсе" дәүләт автономияле учреждениесе
Юридик адресы: 420073, Казан ш., Шуртыгин ур., 22
ИНН 1654017928/ КПП 166001001
Казан ш. "Ак Барс" ХАҖ
Алучы: ТР Финанс Министрлыгы ("Татарстан Республикасының төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя хасил итү идарәсе" дәүләт автономияле учреждениесе
л/с ЛАВ00713002-УЭкспЦен)
и-х/с 40601810700023000003
КПС 71300000000000000130
ОКТМО 92701000
БИК 049205805
К/с 30101810000000000805

**Дәүләт экспертизасы буенча күрсәтелгән хезмәтләрне кабул итү АКТы**

Башкаручы – ____________________ нигезендә гамәл кылучы, ______________ йөзендә "Татарстан Республикасының төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя хасил итү идарәсе" дәүләт автономияле

учреждениесе тапшыра, ә Заказчы – ________________________ йөзендә күрсәтелгән хезмәтләрне кабул итә.

Хезмәтләр ___________ел. № _____ шартнамә нигезендә күрсәтелде.

Исәп-хисап бәясе –

Моннан тыш НДС 18% –

Җәмгысе –

Сыйфаты шартнамә шартларына туры килә. Башкаручы тарафыннан __________ ел, №____ шартнамә буенча бурычлар тулы күләмдә һәм тиешле рәвештә башкарылды, Заказчының ризасызлыклары юк. Актка ________ ел, № ____ дәүләт экспертизасы бәяләмәсе теркәлә.

| | |
|---|---|
| **Заказчы:** | **Башкаручы:** |
| ______________ | _______________ |
| "_______"_________ел. | "______"_________ел"; |

Регламентка 3 нче кушымтаның 1 пунктындагы "з" пунктчасының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"дәүләт катнашында эре инвестиция проектына халыкка ачык технологик аудит үткәрелүе хакында уңай җыелма бәяләмәнең күчермәсе (әгәр дә халыкка ачык технологик һәм бәя аудитын үткәрү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Дәүләт катнашында эре инвестиция проектларына халыкка ачык технологик һәм бәя аудитын үткәрү турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында" 2013 елның 30 апрелендәге 382 номерлы карары белән расланган Дәүләт катнашында эре инвестиция проектларына халыкка ачык технологик һәм бәя аудитын үткәрү турында нигезләмә нигезендә мәҗбүри булса) яисә аңа карата контракт төзү планлаштырыла торган, предметы капиталь төзелеш объектын бер үк вакытта проектлау, төзү һәм эксплуатациягә кертү буенча эшләрне башкарудан гыйбарәт булган капиталь төзелеш объектын төзү буенча инвестиция проектына гамәлгә ашырылучы инвестицияләрне нигезләү һәм, Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары нигезендә инвестицияләрне нигезләүне әзерләү һәм аның технологик һәм бәя аудитын үткәрү мәҗбүри булган очракта, мондый инвестицияләрне нигезләүнең технологик һәм бәя аудиты бәяләмәсенең күчермәсе;"

2. Юридик бүлек башлыгы Э.Ю. Латыйповага дәүләт теркәвенә алу өчен шушы боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторы җитәкчесе Г.С. Миңнехановага бу боерык Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алынган вакыттан соңгы ун эш көне эчендә аның Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы

министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр И.Ә.Фәйзуллин

МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫК МИНИСТРЛЫГЫ *
ОТДЕЛ ОРГАНИЗАЦИОННО-ПРОТОКОЛЬНОЙ РАБОТЫ, КОНТРОЛЯ И ДЕЛОПРОИЗВОДСТВА